| КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
|---|---|---|
| 18.07.2024 | Казан | № 363-П |

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау Комитетының 2022 нче елның 2 нче ноябрендә гамәлгә кергән 411-П номерлы «Мәдәни мирас объектын саклау предметын билгеләү һәм раслау проект документациясен карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында»гы боерыкка үгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау Комитетының 2022 нче елның 2 нче ноябрендә гамәлгә кергән 411-П номерлы «Мәдәни мирас объектын саклау предметын билгеләү һәм раслау проект документациясен карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында»гы боерыкка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2002 елның 25 нче июнендә кабул ителгән 73-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре”, 2010 елның 27 июлендә кабул ителгән 210-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 нче февралендәге 175 нче номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм кабул итү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында” карары, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2016 нчы елның 13 нче гыйнварында гамәлгә кергән 28 нче номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында " 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ

номерлы Федераль законның 64 статьясы нигезендә Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектының сак предметын билгеләү тәртибен раслау хакында»гы боерыгы нигезендә боерам:

әлеге боерык белән расланган, Мәдәни мирас объектын саклау предметын билгеләү һәм раслау проект документациясен карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентыда

2.6.1 пунктының дүртенче абзацында, 2.6.2 пунктының җиденче абзацында, 2.13.1 пунктының дүртенче һәм җиденче абзацларында, 2.14.4 пунктының бишенче һәм җиденче абзацларында, 3.9.1 пунктының бишенче абзацында «Бердәм портал» сүзен туры килгән килешләрдә төшереп калдырырга;

3.5.1.1 пунктының унберенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3.5.1.2 пунктының беренче абзацында «3.5.2» саннарын «3.5.1» саннарына алмаштырырга;

кушымтаны (белешмә) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Хокук, кадрлар, мобилизация һәм оештыру эшләре бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәве узарга җибәрүне тәэмин итәргә.

3. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин